ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.21 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.21 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертергә.
2. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.21 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 30 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законның $1^2$ статьясы нигезендә рәсми бәяләмә алу өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенә җибәрергә.
3. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.21 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең рәсми бәяләмәсен алганнан соң, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.
4. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының әлеге закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.
5. Күрсәтелгән закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт

Советының рәсми вәкиле итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын билгеләп куярга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәмммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 24 декабре
№ 243-VI ДС